КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 апрель г.Казань № 423

Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Совет һәм Россия дәүләт эшлеклесе, эчке хезмәт генерал-лейтенанты Николай Иванович Демидов истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Н.И.Демидовка Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 17 нче йорт адресы буенча бина фасадына татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«Бу йортта 1979 – 1983 елларда<br>ТАССРның 1978 – 1983 еллардагы<br>эчке эшләр министры,<br>СССРның 1983 – 1991 еллардагы<br>эчке эшләр министры урынбасары<br>генерал-лейтенант<br>Николай Иванович Демидов<br>яшәде

В этом доме в 1979 –1983 гг. жил
министр внутренних дел ТАССР
в 1978 – 1983 гг., заместитель
министра внутренних дел СССР
в 1983 – 1991 гг.
генерал-лейтенант
Николай Иванович Демидов».

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә мемориаль тактаның баланста тотучысын билгеләүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин